**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
422870, С.Базарные Матаки,
ул. С.Крайнова, д.58

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С. Крайнов ур., 58

Телефон: (84346) 20-0-26, 21-0-48, факс: (84346) 21-7-57. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: alkeevskiy.tatarstan.ru.

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Базарлы Матак авылы

2023 елның 23 марты 162№

2023 елда Татарстан Республикасы Әлки
муниципаль районы муниципаль берәмлек-
ләренең җирле үзидарә органнарында
муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы, 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы, 2022 елның 4 ноябрендәге «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 22 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 424-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 21.11.2022 елның 21 ноябрендәге 28-7/В16053 номерлы хаты, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе җитәкчесенең 2023 елның 4 гыйнварындагы «2023 елда Татарстан Республикасында муниципаль берәмлек хезмәте вазыйфасына билгеләп куюу турында» 424-02-3 номерлы хатын үтәү йөзеннән, «Әлки муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча җирле үзидарә органнарында һәм Әлки муниципаль районының муниципаль органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин дип билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пункты Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләнгәндә кулланылмый.

3. Әлеге карарны «Татмедиа» АҖ филиалының Әлки районы «Әлки хәбәрләре» («Алькеевские вести») газетасында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.https://pravo.tatarstan.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башлыгы урынбасары Р.А. Билаловка йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль районы Башлыгы А. Ф. Никошин